МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.04.2026 Казан шәһәре 61

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында бурыч йөкләмәләрен үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдаланып башкарыла торган, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Рәсәй Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше һәм Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 7 февралендәге 132 номерлы карары белән расланган Рәсәй Федерациясе затлары һәм гражданнары вазыйфаларын дәүләт серенә кертү кагыйдәләре нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының кушымтада бирелә торган исемлеген расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Садыйкова В.Р.) әлеге боерыкны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының “Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 19.01.2024 № 14 боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары-министр**

**М. Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
16.04.2026 № 61 боерыгы белән
расланды.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган, билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

Вазыйфа исеме

| | **Саны (берәмлекләр)** |
|---|---|
| Җитәкчелек | |
| Эшләр белән идарә итүче | 1 |
| Юридик бүлек | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Әйдәүче киңәшче | 1 |
| Финанс исәбен алу һәм хисаплылык бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Әйдәп баручы белгеч | 3 |
| Мобилизацион әзерлек секторы | |
| Сектор мөдире | 1 |
| Әйдәүче киңәшче | 1 |
| Дәүләт идарәсен камилләштерү бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Макроикътисадый фаразлау бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Әйдәүче киңәшче | 1 |
| Әйдәүче консультант | 1 |
| Икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |

| | |
|---|---|
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Әйдәүче киңәшче | 1 |
| Социаль-икътисадый мониторинг департаментының мәгълүмат ресурслары идарәсенең мәгълүмат ресурслары һәм технологияләре, икътисадый анализ һәм социаль үзгәрешләрне тикшерү бүлеге | |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| Социаль-икътисадый мониторинг департаменты муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәле мониторингы бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Оештыру эше бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| Мәгълүматлаштыру бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| Әйдәп баручы белгеч | 2 |
| 1 разрядлы өлкән белгеч | 1 |
| Эшчәнлекне һәм сатып алуларны тәэмин итү бүлеге | |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| БАРЛЫГЫ: | 33 |